Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аксубай муниципаль районы
Иске Илдеряк авыл җирлеге башлыгы

# КАРАРЫ

№8 17.10.2022 ел

«Иске Ильдеряк авылында халык җыенын билгеләү турында
Аксубай муниципаль районы
Иляшкино авыл җирлегендә
Халыкның үзара салым чараларын кертү һәм
куллану мәсьәләсе буенча»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Аксубай муниципаль районы «Иске Ильдеряк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2022 елның 27 октябрендә 13 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Аксубай районы, Иляшкино авылы, Көнбатыш урамы, 20 адресы буенча КФҮ бинасында Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Ильдеряк авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрелә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Сез 2023 елда Аксубай муниципаль районының Иске Ильдеряк авыл Иляшкино авыл территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән; I группа Инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 650 сум күләмендә үзара салым кертү турында килешәсезме, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерелгә:

**1) Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**

- вак таш түшәлгән юл полотносын урнаштыру (грунтлау, градирование, вак таш салу, килешү буенча эш хакы түләү, вак таш сатып алу;
- кышкы юлларны карап тоту (кышкы чорда юлларны кардан чистарту - килешү буенча эшләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу).

**2) Күрсәтелгән Кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:**

- җәйге чорда территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып
-трактор һәм аларга комплектлаучылар өчен асылмалы җиһазлар сатып алу.

**3) Туплау (шул исәптән аерым туплау) һәм ТКО транспортлау эшчәнлеген оештыруда катнашу:**

- контейнерлар сатып алу, контейнер киртәләре урнаштыру (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү).

**4) Жирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итү Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру:**

- су челтәрен ремонтлау, Иляшкино торак пунктындагы су башнясын һәм насос бүлмәсен коймалау (материаллар сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

**5) Ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын тоту:**

- зиратларны төзекләндерү һәм карап тоту (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

«РИЗА» «РИЗА ТҮГЕЛ»

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru шулай ук Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмат-коммуникация челтәрендә авыл җирлегендә яшәүчеләр күпләп җыелган урыннарда, стендларда һәм белдерү такталарында эленү юлы белән халыкка җиткерергә, шулай ук Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга кирәк.

4.Әлеге карар аның басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

ТР Аксубай муниципаль районы
Иске Ильдерәк авыл җирлеге
башлыгы: С. М. Маклаков